МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛАГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от “12” 11.2014 №376

Казан ш.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм
юл хуҗалыгы министрлыгының
2014 елның 07 июлендәге №214
Татарстан Республикасы Транспорт һәм
юл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы
белән расланган Пассажирларны һәм багажны
җиңел такси белән ташу өлкәсендә
төбәкара дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен үтәүгә карата
административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2014 елның 07 июлендәге №214 Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган Пассажирларны һәм багажны җиңел такси белән ташу өлкәсендә төбәкара дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүгә карата административ регламентына (алга таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.7.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 нче пунктча белән тулыландырырга:

“5) Россия Федерациясе Президенты каршында эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яки Татарстан Республикасы Президенты каршында эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.”;

5.2.2.4 пунктының өченче абзацындагы “электрон сан имзасы белән” сүзләрен “көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән” сүзләренә алмаштырырга”;

Административ регламентның 3 нче һәм 4 нче кушымталарын әлеге боерыкка карата 1 нче һәм 2 нче кушымталарга туры китереп яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Транспорт идарәсе башлыгы А.В. Сидоровка йөкләргә.

Министр Л.Р. Сафин

“Татарстан Республикасы Транспорт һәм
юл хуҗалыгы министрлыгының
2014 елның 12 ноябрендәге
№376 боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Транспорт һәм
юл хуҗалыгы министрлыгының Пассажирларны
һәм багажны җиңел такси белән ташу өлкәсендә
төбәкара дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен үтәүгә карата
административ регламентына
3 нче кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы Транспорт һәм
юл хуҗалыгы министрлыгы
420061, Казан ш., Н. Ершов ур., 31 а й.

**Административ хокук бозу турында**
**№_______ БЕРКЕТМӘ**

**20___ елның “__” _________ _____ сәг._____мин.** ____________________________
(тотыру урыны)

______________________________________________________________________
(беркетмәне төзүче вазифаи затның вазифасы, фамилиясе һәм инициаллары)
______________________________________________________________гамәлгә ашырганда
түбәндәге граждан(ка)ның (вазифаи затның, юридик затның)_________________________
______________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган урыны, аның законлы вәкиле турында белешмәләр)
Тору урыны (адресы, телефоны)______________________________________________
Эш урыны (адресы, телефоны) ______________________________________________
түбәндәге җинаятьне
кылган_____________________________________________________________
(административ хокук бозуның урыны, вакыты һәм вакыйгасы турында белешмәләрне, рөхсәт номерын һәм датасын күрсәтергә)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________ беркетмә төзеде,
аның өчен РФ КоАП _______________ буенча җаваплылык каралган.

Граждан(ка)ның (вазифаи затның, юридик затның) аңлатмалары ______________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(фамилиясе, инициаллары)

____________________________________________
(гражданның, вазифаи затның, законлы вәкиленең имзасы)

Шаһитлар, зыян күрүчеләр (булган очракта):
1. ________________________________________ ____________________
(таныклаучылар) (фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәгән урыны, телефоны) (имзасы)

2. ________________________________________ ____________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәгән урыны, телефоны) (имзасы)

Әлеге беркетмә РФ КоАП 28.2 статьясы нигезендә аңа карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган зат (аның законлы вәкиле) катнашында төзелде, аңа РФ КоАП 25.1 (24.2, 25.3, 25.4, 25.5, 28.2) статьяларында каралган хокуклары һәм бурычлары аңлатылды һәм ул 17.7 статья буенча җаваплылык турында кисәтелде.

____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(яклаучының яки законлы вәкиленең фамилиясе, инициаллары, ордер яки ышанычнамә белешмәләре)

____________________________________________
(гражданның, вазифаи затның, законлы вәкиленең имзасы)

Беркетмәгә түбәндәге документлар (дәлилләр) теркәлә:
1)__________________________________________________________________________
(беркетмәгә теркәлә торган дәлилләрне, зыян күрүченең һәм шаһитларның күрсәтүләрен, эксперт бәяләмәсен күрсәтергә)

Беркетмә тәрҗемәче катнашында төзелде________________________________________
(Ф.И.А., яшәү урыны адресы, телефоны)

Эш 20___ елның "__" ________________ ___сәг.___мин.,_____________________________
_______________________________________________ адресы буенча карап тикшереләчәк.

№__ беркетмә белән таныштым һәм аның күчермәсен алдым "__"__________20__ ел.

________________________________________ ______________________________________
(беркетмә төзүче затның имзасы) (гражданның, вазифаи затның, законлы вәкиленең имзасы)

Хокук бозган зат танышып чыгудан баш тартты:
____________________________________________________________________________

Беркетмәнең күчермәсе 20___ елның "__" __________ почта аша җибәрелде.

____________________________________________
(беркетмәне җибәрүче затның имзасы, фамилиясе, инициаллары)

**24.2 статья. Административ хокук бозулар турында эшләр алып барыла торган тел**

1. Административ хокук бозулар турындагы эшләр Россия Федерациясенең дәүләт теле – рус телендә алып барыла. Россия Федерациясенең дәүләт теле белән берлектә административ хокук бозулар турында эш административ хокук бозулар турында эшне карап тикшерүгә вәкаләтле судья, орган, вазифаи зат урнашкан территория караган республиканың дәүләт телендә дә алып барылырга мөмкин.

2. Административ хокук бозу турында эш алып баруда катнашучыга һәм эш алып барыла торган телне белмәгән затларга туган телләрендә яки күрсәтелгән затлар ирекле сайлаган теләсә кайсы башка телдә чыгыш ясау һәм аңлатмалар бирү, үтенечнамәләр җиткерү һәм каршы килү, шикаятьләр китерү, һәм шулай ук тәрҗемәче хезмәтләреннән файдалану хокукы бирелә.

**25.1 статья. Аңа карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган зат**

1. Аңа карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган зат эш материаллары белән танышырга, дәлилләр китерергә, үтенечнамәләр җиткерергә һәм каршы чыгарга, аңлатмалар бирергә, яклаучының юридик ярдәменнән файдаланырга, шулай ук әлеге Кодекс нигезендә башка процессуаль хокуклардан файдаланырга хокуклы.

2. Административ хокук бозу турында эш аңа карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган зат катнашында карап тикшерелә. Күрсәтелгән заттан башка эш бары тик әлеге Кодексның 28.6 статьясының 3 өлешендә каралган очракларда гына, яисә затка эшне карап тикшерүнең урыны һәм вакыты турында тиешенчә хәбәр ителү турында мәгълүматлар булса һәм заттан эшне карап тикшерүне кичектерү турында үтенечнамә җиткерелмәсә яки мондый үтенечнамә канәгатьләндерелмәсә карап тикшерелә ала.

3. Административ хокук бозу турында эшне карап тикшерүче судья, орган, вазифаи зат аңа карата эш алып барылган затның эшен карап тикшергәндә катнашуын мәҗбүри итеп танырга мөмкин. Административ арестка, чит ил гражданын яки гражданлыгы булмаган затны Россия Федерациясе чикләренә административ куып чыгаруга яки мәҗбүри эшләргә сәбәп була торган административ хокук бозу турында эшне карап тикшергәндә аңа карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган затның катнашуы мәҗбүри булып тора.

4. Аңа карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган балигъ булмаган зат, болар хакында фикер алышу күрсәтелгән затка тискәре йогынты ясарга мөмкин булган эш шартлары карап тикшерелгән вакытка чыгарылып торырга мөмкин.

**25.3 статья. Физик затның законлы вәкилләре**

1. Аңа карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган балигъ булмаган яисә үзенең физик яки психик хәле буенча үз хокукларын мөстәкыйль гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмаган физик затның яки зыян күрүченең законлы хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен аларның законлы вәкилләре гамәлгә ашыра.

2. Физик затның ата-анасы, уллыкка (кызлыкка) алучылары, опекуннары яки попечительләре законлы вәкилләре була.

3. Физик затның законлы вәкилләре булган затларның туганлык җепләре яки тиешле вәкаләтләре законнарда каралган документлар белән таныклана.

4. Аңа карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган физик затның һәм зыян күрүченең законлы вәкилләре, үзләре вәкиллек итүче затларга карата әлеге Кодекста каралганча хокукларга ия һәм җаваплы була.

5. Унсигез яшькәчә булган зат кылган административ хокук бозу турында эшне карап тикшергәндә, административ хокук бозуны карап тикшерүче судья, орган, вазифаи зат күрсәтелгән затның законлы вәкиленең катнашуын мәҗбүри дип танырга хокуклы.

**25.4 статья. Юридик затның законлы вәкилләре**

1. Аңа карата административ хокук бозу турында эш алып барылган юридик затның яки зыян күрүче юридик затның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау аның законлы вәкилләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Кодекс нигезендә аның җитәкчесе, һәм шулай ук закон яки юридик затның гамәлгә кую документлары нигезендә танылган башка зат юридик затның законлы вәкилләре булып санала. Юридик затның законлы вәкиленең вәкаләтләре аның вазифаи хәлен таныклый торган документлар белән раслана.

3. Юридик зат кылган административ хокук бозу турында эш аның законлы вәкиле яки яклаучысы катнашында карап тикшерелә. Күрсәтелгән затлардан башка эш бары тик әлеге Кодексның 28.6 статьясының 3 өлешендә каралган очракларда, яисә затларга эшне карап тикшерүнең урыны һәм вакыты турында тиешенчә хәбәр ителү турында мәгълүматлар булса һәм алардан эшне карап тикшерүне кичектерү турында үтенечнамә җиткерелмәсә яки мондый үтенечнамә канәгатьләндерелмәсә карап тикшерелә ала.

4. Юридик зат кылган административ хокук бозу турында эшне карап тикшергәндә административ хокук бозу турында эшне алып бару алар хөкемендә булган – судья, орган, вазифаи зат юридик затның законлы вәкиленең катнашуын мәҗбүри итеп танырга хокуклы.

**25.5 статья. Яклаучы һәм вәкил**

1. Аңа карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган затка юридик ярдәм күрсәтү өчен административ хокук бозу турында алып барылучы эштә яклаучы, зыян күрүчегә юридик ярдәм күрсәтү өчен – вәкил катнаша ала.

2. Административ хокук бозу турында эшне алып баруда катнашуга яклаучы яки вәкил сыйфатында адвокат яки башка зат рөхсәт ителә.

3. Адвокатның вәкаләтләре тиешле адвокатлык оешмасы тарафыннан бирелгән ордер белән таныклана. Юридик ярдәм күрсәтүче башка затның вәкаләтләре закон нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә белән таныклана.

4. Яклаучы һәм вәкил административ хокук бозу турында алып барыла торган эштә катнашуга административ хокук бозу турында эш ачылган мизгелдән кертелә.

5. Административ хокук бозу турында алып барыла торган эштә катнашуга кертелгән яклаучы һәм вәкил эшнең барлык материаллары белән танышырга, дәлилләр китерергә, үтенечнамәләр җиткерергә һәм каршы чыгарга, эшне карап тикшерүдә катнашырга, алып барылган эшне тәэмин итү буенча күрелгән чараларны шикаять кылырга, әлеге Кодекс нигезендә башка процессуаль хокуклардан файдаланырга хокуклы.

**17.7 статья. Административ хокук бозу турында эш алып баруны гамәлгә ашыручы прокурорның, тикшерүченең, дознавательнең яки вазифаи затның законлы таләпләрен үтәмәү**

Прокурорның федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләреннән килеп чыга торган таләпләрен, һәм шуңа бәрабәр административ хокук бозу турында эш алып баручы тикшерүченең, дознавательнең яки вазифаи затның таләпләрен белә торып үтәмәү, –

гражданнарга – бер мең сумнан бер мең биш йөз сумга кадәр; вазифаи затларга – ике мең сумнан өч мең сумга кадәр; юридик затларга илле мең сумнан йөз мең сумга кадәр административ штраф салынуга яки эшчәнлеген туксан тәүлеккә кадәр административ туктатып торуга сәбәп була.”

"Татарстан Республикасы Транспорт һәм
юл хуҗалыгы министрлыгының
2014 елның 12 ноябрендәге
№376 боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Транспорт һәм
юл хуҗалыгы министрлыгының Пассажирларны
һәм багажны җиңел такси белән ташу өлкәсендә
төбәкара дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен үтәүгә карата
административ регламентына
4 нче кушымта

Рәвеше

**Татарстан Республикасы Транспорт һәм**
**юл хужалыгы министрлыгы**
420061, Казан ш., Н. Ершов ур., 31 а й.

Административ хокук бозу турында эш буенча
№____ КАРАР

« » __________ 20___ел. ________________________________
(карап тикшерү урыны)

____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(карар чыгарган затның вазифасы, фамилиясе һәм инициаллары, адресы)
түбәндәге административ хокук бозу(лар)ны ________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(законнарны бозуга китергән хокук бозуның вакыты, урыны, асылы турында кыскача бәян итү)
____________________________________________________________________________кылучы,

20___ елның "__"_________ №_____ беркетмә ____________________________________
____________________________________________________________________________
(норматив-хокукый актның исеме)
_______________________________________________________________ ст. бозылган,
моның өчен Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының _______ ст._______ өлеше буенча административ җаваплылык каралган, түбәндәгенең
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(гражданның, вазифаи затның, юридик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
_____________ административ хокук бозуы турында эш материалларын карап тикшереп,

АЧЫКЛАДЫ:

____________________________________________________________________________
(гражданның, вазифаи затның, юридик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
____________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________сум күләмендә штраф салырга.

Административ хокук бозу турында эш буенча әлеге карар карарның күчермәсен алган көннән ун көн дәвамында судта шикаять итәлергә мөмкин. Вакыты узганнан соң шикаять ителмәгән яки ризасызлык белдерелмәгән административ хокук бозу турындагы эш буенча карар законлы көченә керә һәм башкаручыга җибәрелә.

Административ штраф административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан административ штраф салыну турында карар законлы көченә кергән көннән башлап алтмыш көннән соңга калмыйча түләнергә тиеш (РФ КоАП 32.2 ст. 1 п.).

Административ штраф вакытында түләнмәгәндә, РФ КоАП 32.2 ст. һәм 20.25 ст. 1 өлеше нигезендә штраф суммасы икеләтелгән күләмдә мәҗбүри түләттерүгә сәбәп була.

Карар белән таныштым һәм
күчермәсен алдым

____________________________________ ____________________________________
(карарны кабул иткән вазифаи затның имзасы) (хокук бозучының имзасы, дата)

М.У.

_______________________________________________________________________________

Түләүне алучы: